ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.09.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1829**

Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында

Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Чапаев урамы, 40А йорты адресы буенча урнашкан, 16:49:010617:18 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы Н.Б. Гайнанованың мөрәҗәгатен карап чыгып, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кишәрлек чикләреннән көнбатыш яктан 3 метрдан 0 метрга кадәр һәм көнчыгыш яктан 3 метрдан 0 метрга кадәр минималь чигенүләрне киметү өлешендә, Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Чапаев урамы, 40А йорты адресы буенча урнашкан, 16:49:010617:18 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан читкә тайпылуга Н.Б. Гайнановага рөхсәт бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников